**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Пычак авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**12 ноябрь, 2020 ел** **№4**

**«Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Әсән-Елга авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 27 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Әсән-Елга авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Әсән-Елга авылы, Әхмәт Юныс урамы, 52а йорты адресы буенча урнашкан мәчет бинасында үткәрергә.

2. 2020 елның 27 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Әсән-Елга авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Әсән-Елга авылы, Әхмәт Юныс урамы, 52а йорты адресы буенча урнашкан мәчет бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм катнашучылар, I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар, студентлар (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Әсән-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Әсән-Елга авылында тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча хезмәт күрсәтүләр һәм эшләр өчен түләү);
- Әсән-Елга авылында Яшьләр, Мәхмүт Яхин урамнарында юлларны асфальтлау;
- Әсән-Елга авылы зираты өчен материал сатып алу;
- Әсән-Елга авылы зираты коймаларын төзү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Әсән-Елга авылына су тараткыч башнялар өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, эшләр өчен килешү буенча түләү;
- урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;
- янгын инвентаре сатып алу;
- территорияне төзекләндерү, килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Әсән-Елга авылының Яшьләр, Яр буе урамнарындагы юлларга вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Әсән-Елга авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Пычак авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Пычак авыл җирлеге
башлыгы: Г.Ш. Нәфыйков